ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 11.02.2020 КАРАР ПР-20

## Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы хезмәтне саклау буенча координация советы турында

Хезмәт куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм җитештерүдәге имгәнүләрне киметү, гражданнарның хезмәт хокукларын үтәү өлешендә эш бирүчеләрнең җаваплылыгын арттыру максатларында Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

- Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы хезмәтне саклау буенча координация советы турында Нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә;

- Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы хезмәтне саклау буенча координацион совет составын, 2 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.Р.Сираевага йөкләргә.

Җитәкче И.И.Габдулхаев

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты карарына
02.__.20 №ПР-20
1 нче санлы кушымта

**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ КАРШЫНДАГЫ ХЕЗМӘТНЕ САКЛАУ БУЕНЧА КООРДИНАЦИОН СОВЕТЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Актаныш муниципаль районы башлыгы каршындагы хезмәтне саклау буенча координация советы (алга таба - Совет) Актаныш муниципаль районында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында төзелә.

2. Совет җирле үзидарә органнарының эш бирүчеләр, оешмаларның хезмәтне саклау, күзәтчелек һәм контроль өлкәсендә дәүләт идарәсе органнары, социаль иминият фонды, профсоюз берләшмәләре һәм башка иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген тормышка ашыра.

3. Совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, хезмәтне саклау өлкәсендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының закон чыгару һәм башка норматив-хокукый актларына, шулай ук әлеге типлаштырылган Нигезләмәгә таяна.

4. Советның төп бурычлары булып торалар:

хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру эшчәнлеген координацияләү;

эш бирүчеләрнең хезмәтне саклау таләпләрен үтәвен контрольдә тоту;

эш урыннарында хезмәткәрләрнең куркынычсыз шартларга һәм хезмәтне саклауга хокукларын яклау;

төрле милек формасындагы оешмаларда хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау торышын анализлау һәм аларны яхшырту буенча чаралар күрү;

хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча территориаль программаларны эшләү һәм кабул итү;

оешмаларның җитәкчеләре һәм белгечләре, хезмәтне саклау өлкәсендә хезмәт күрсәтүче башкарма хакимият органнары, оешмалар һәм лабораторияләр вәкилләре, фәнни оешмалар, медицина учреждениеләре, хезмәтне саклау буенча уку үзәкләре, шулай ук хезмәтне саклау буенча башка чаралар катнашында семинарлар, киңәшмәләр, "түгәрәк өстәлләр", "хезмәтне саклау көннәре" үткәрү;

барлык оештыру-хокукый формадагы һәм милек рәвешләрендәге оешмалар арасында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча эшләрне иң яхшы оештыруга смотр-конкурслар үткәрү.

5. Совет үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә:

хезмәтне саклау турында гамәлдәге законнарны гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләрне карый;

хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча территориаль программаларны эшләү өчен эшче төркемнәр төзи;

хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча территориаль программаларны гамәлгә ашыруны контрольдә тота;

Совет әгъзаларының төрле милек формасындагы оешмалар белән хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау торышын өйрәнү һәм анализлау, аларны яхшырту буенча чаралар күрү максатыннан очрашуларын планлаштыра;

авыр эш, зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары, шул исәптән сөт яки башка тигез бәяле азык-төлек продуктлары белән эшләгән өчен эш бирүчеләргә компенсацияләр бирүнең дөреслеге мәсьәләләрен карый;

хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча иң яхшы оештырылган смотр-конкурсларда барлык оештыру-хокукый формадагы һәм милек рәвешләрендәге оешмаларның катнашуын оештыра;

барлык оештыру-хокукый формадагы һәм милек рәвешләрендәге оешмалар арасында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча иң яхшы оештырылган смотр-конкурсларда җиңүчеләрне билгели;

хезмәтне саклау һәм җитештерү санитариясе өлкәсендә алдынгы методларны һәм профилактик эш формаларын кертү мәсьәләләре буенча оешмаларга ярдәм итә;

50 дән артык кеше эшли торган оешмаларда хезмәтне саклау хезмәтләрен булдыруга булышлык итә;

төркемле бәхетсезлек очракларының, үлем белән тәмамланган бәхетсезлек очракларының сәбәпләрен һәм аларны бетерү буенча күрелә торган чараларны карый;

производствода имгәнү, авариялелек һәм һөнәри авырулар санын арттыруга юл куйган яки югары дәрәҗәгә ия булган оешмаларда күзәтчелек һәм контроль органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләрен карый;

барлык милек формасындагы оешмаларда хезмәт шартлары буенча эш урыннарын аттестацияләү үткәрүне активлаштыруга ярдәм итә;

үз утырышларында эш бирүчеләрнең эш урыннарында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча күрелә торган чаралар турында тыңлый;

Татарстан Республикасында дәүләт хезмәт инспекциясе, прокуратура, Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор органнарына, хезмәтне саклау турындагы законнар таләпләрен бозуга юл куйган эш бирүчеләргә карата чаралар күрү турында күзәтчелек һәм контрольнең башка органнарына, җитештерү травматизмы һәм һөнәри авыру дәрәҗәсенең югары булуы турында тәкъдимнәр кертә;

куркынычсыз технологияләр һәм җитештерү чаралары кертүче эш урыннарында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча уңай тәҗрибәгә ия эш бирүчеләрне бүләкләү турында муниципаль район (шәһәр округы) башлыгына тәкъдимнәр кертә;

оешмаларда хезмәтне саклау буенча күмәк килешүләр һәм килешүләр төзү, җитәкчеләрне һәм белгечләрне хезмәтне саклау, эшләүчеләрне махсус кием, махсус аяк киеме һәм башка индивидуаль саклану чаралары белән тәэмин итү буенча эшләрнең агымдагы торышын карый;

хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча илебезнең һәм чит илләрнең алдынгы тәҗрибәсен таратуга ярдәм итә.

6. Совет рәисе булып муниципаль район башлыгы яисә муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе (яисә аның хезмәтне саклау мәсьәләләрен алып баручы урынбасарларының берсе) торырга мөмкин.

7. Совет составы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчесе карары белән раслана. Совет составына җирле үзидарә органнары вәкилләре, төрле милек формасындагы оешмалар җитәкчеләре һәм белгечләре, Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясе, Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор, социаль иминият фондының җирле органнары, профсоюзлар һәм башка иҗтимагый оешмалар вәкилләре керә ала (килешү буенча).

8. Совет үз эшчәнлеген Совет утырышында кабул ителә һәм муниципаль район (шәһәр округы) башлыгы тарафыннан раслана торган эш планы нигезендә гамәлгә ашыра.

9. Совет утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

10. Совет утырышлары кварталга кимендә 1 тапкыр үткәрелә.

11. Совет карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, әгәр алар өчен Совет утырышында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә,

12. Совет утырышлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларга рәис һәм секретарь кул куя.

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты карарына
02.2020 № ПР-20
2 нче санлы кушымта

Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты каршындагы хезмәтне саклау буенча координация советы

| | |
|---|---|
| Габдулхаев И.И. | Координация советы рәисе, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| Сираева Л.Р. | Координация советы рәисе урынбасары, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары |
| Мирзашарипова О.М | Координация советы секретаре, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге начальнигы |
| Координация советы әгъзалары: | |
| Гарипов Р. И. | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары |
| Әбүдаров Ф. А. | "УКС" МУП директоры |
| Хуҗәхмәтова Г. Ф. | Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Актаныш муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесе |
| Касыймова Д. Р. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Игелек үзәге" халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт автоном учреждениесе директоры |
| Мансуров А. М. | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының социаль һәм агарту эшләре бүлеге начальнигы |
| Мугтазиров Р. А. | "Актаныш РҮХ" ДАССУнең баш табиб урынбасары |
| Карамов А. С. | Актаныш муниципаль районы "Мәгариф идарәсе" МКУ баш белгече |
| Иманаев А. И. | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге начальнигы |
| Салихов Н. М | "Актаныш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" дәүләт бюджет учреждениесе директоры |
| Шәйхетдинов Р. С. | Актаныш районы агросәнәгать комплексы профсоюз хезмәткәрләренең район комитеты рәисе |
| Хафизова Л.М. | Баш дәүләт санитария табибы урынбасары Яр Чаллы шәһәре, Тукай, Мөслим, Минзәлә, Актаныш районнары |
| Сәлимгараев Н.А. | Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең җитештерү-маркетинг бүлегенең механикалаштыру буенча консультанты |
| Сарваров И.Х. | Муниципаль район башлыгының коррупциягә |

| | |
|---|---|
| Нәҗмиев Ф.О. | Социаль иминият фондының төбәк бүлекчәсе дәүләт учреждениесенең 15 нче филиалы директоры |
| Яппаров Ф.И. | Актаныш муниципаль районында Татарстан Республикасы профсоюз оешмасының штаттан тыш хокукый инспекторы |
| Йосыпов Ф. Р. | Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Минзәлә районара тикшерү бүлеге җитәкчесе |